ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июнь 2020 ел №2836

Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174.3 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте инспекциясенә, агымдагы елның 1 сентябренә кадәр, хисап финанс елы һәм хисап елына кадәрге ел өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүматны Башкарма комитетка җибәрергә тәкъдим итәргә:

1) ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;

2) Яр Чаллы шәһәре бюджетының һәр салым чыгымы буенча алынып бетмәгән керемнәр суммасы турында;

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары Н.А. Кропотовага, И.З. Исхаковка, Р.М. Хәлимовка, Э.Ф.Тимергалиевка, җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 15 июнендәге
2836 номерлы карарына
кушымта

## Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр нигезендә, Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программаларның максатларыннан, муниципаль программаларның структур элементларыннан һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү максатында Башкарма комитетның тармак органнары:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыралар;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыралар.

### 2 бүлек. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру

4. Башкарма комитетның тармак органы, агымдагы елның 1 маена кадәр срокта, чираттагы финанс елына һәм план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыра һәм Башкарма комитетның финанс идарәсе белән килештерә.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеге агымдагы елның 15 июненә кадәр Башкарма комитет карары белән раслана һәм агымдагы елның 1 июленнән соңга калмыйча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү максатында Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының финанс идарәсе ел саен 1 сентябрьгә кадәр, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең тиешле салым чыгымнары шартларын билгели торган, шул исәптән хисап елында һәм хисап елыннан алдагы елда гамәлдә булган норматив хокукый актларын һәм әлеге тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны күрсәтеп, түләүчеләрнең категорияләре турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте инспекциясенә җибәрә.

### 3 бүлек. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе

6. Салым чыгымнарын бәяләү Башкарма комитетның тармак органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләү;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү.

7. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының максатчанлыгын бәяләү;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү.

8. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

2) салым түләүчеләрнең ташламалардан файдалану хокукына ия булган түләүчеләр саны һәм бишьеллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны чагыштырмасында характерлана торган салым ташламаларына ихтыяҗы.

9. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары әлеге тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән критерийларның берсенә булса да туры килмәгән очракта, Башкарма комитетның тармак органы Башкарма комитет Җитәкчесе адресына түләүчеләр өчен ташламаларны саклау (аныклау, гамәлдән чыгару) турында тәкъдимнәр җибәрә.

10. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымының нәтиҗәлелек критерие буларак, муниципаль программа максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең ким дигәндә бер күрсәткече (индикаторы) яисә зурлыгына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары тәэсир итә торган башка күрсәткеч (индикатор) билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елына, хисап елыннан алдагы елга, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеләнә.

11. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

12. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү максатында Башкарма комитетның финанс идарәсе муниципаль программа максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларына карамаган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә һәм ташламаларны бирү нәтиҗәлелегенә чагыштырма анализны гамәлгә ашыра.

13. Чагыштырма анализ, муниципаль программа максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын кулланган очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламалар күләмен чагыштыруны (муниципаль программа максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары 1 сумга һәм альтернатив механизмнарны кулланган очракта, шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет чыгымнары 1 сумга арту күрсәткечен (индикаторын) исәпләү) үз эченә ала.

14. Муниципаль программа максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында шул исәптән түбәндәгеләр исәпкә алынырга мөмкин:

1) ташламаларга хокукы булган түләүчеләргә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына субсидияләр яки турыдан-туры финанс ярдәменең башка формалары;

2) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

3) ташламаларга хокукы булган түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә норматив җайга салуны һәм (яки) контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

15. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү агымдагы елның 1 ноябренә кадәр гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү өчен күрсәткечләр Исемлеге буенча мәгълүмат;

2) салым чыгымының максатчан характеристикаларына ирешү (ирешмәү) турында, муниципаль программа максатларына һәм (яки) социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә салым чыгымының кертеме турында нәтиҗәләрне үз эченә алган язмача аңлатмалар;

3) аларга ирешү өчен нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнар булу (булмау) турында тәкъдимнәр;

4) салым чыгымнарын саклау, аныклау (гамәлдән чыгару), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

16. Башкарма комитетның тармак органы, агымдагы елның 1 октябренә кадәр срокта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәргәндә исәпкә алына торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Яр Чаллы шәһәренең
салым чыгымнары
исемлеген формалаштыру
һәм салым чыгымнарын
бәяләү тәртибенә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр
исемлеге

| Күрсәткечнең исеме | | Мәгълүматлар чыганагы |
|---|---|---|
| I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан характеристикасы | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнар буенча азат итүләрне һәм башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Шәһәр Советы карары |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат итүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Шәһәр Советы карары |
| 3. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Шәһәр Советы карары |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнар буенча азат итүләрне һәм башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Шәһәр Советы карары |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, салымнар буенча азат итүләргә һәм бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлгә керү датасы | Шәһәр Советы карары |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, салымнар буенча азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Шәһәр Советы карары |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, салымнар буенча азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Шәһәр Советы карары |
| 8. | Салым ташламаларының, салымнар буенча азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең исеме | Шәһәр Советы карары |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Салым чыгымының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яки техник ташлама) | Башкарма комитетның финанс идарәсе |
| 10. | Салым түләүчеләр өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр бирү максатлары | Шәһәр Советы карары |
| 11. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр каралган салым исемнәре | Шәһәр Советы карары |
| 12. | Башка түләүчеләр белән чагыштырганда, салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән өстенлекләрнең үзенчәлекләрен билгели торган салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм башка преференцияләрнең төре | Шәһәр Советы карары |
| 13. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат итүләр һәм башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме | Шәһәр Советы карары |
| 14. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат итүләр һәм башка преференцияләр бирелү сәбәпле, муниципаль программалар максатларына һәм (яки) муниципаль берәмлекнең дәүләт программаларына карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) | Башкарма комитетның тармак органы |
| II. Салым чыгымының фискаль характеристикалары | | |
| 15. | Хисап елы өчен һәм хисап елыннан алдагы ел өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләме (мең сум) | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте инспекциясе килешү буенча |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сум) | Башкарма комитетның тармак органы һәм финанс идарәсе |
| 17. | Муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән салым ташламасыннан, азат итүдән һәм башка преференцияләрдән (берәмлекләрдән) файдаланган салым түләүчеләр саны | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре буенча Федераль салым хезмәте инспекциясе килешү буенча |
| 18. | Салым чыгымының нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәсе | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |